ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

25.12.2019 Казан шәһәре **№** 568

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Товарларга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның күләме нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 5 февралендәге 29 номерлы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.03.2016 №50, 31.01.2017 №16, 07.08.2017 №190, 28.09.2018 №266, 14.12.2018 №425, 04.10.2019 №297 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) боерыгы белән расланган Товарларга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның күләме нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктта:

икенче абзацта «административ практика бүлеге» сүзләрен «контроль-ревизия бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы) (Российская газета, 2001, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 23, 2381 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Российская газета, 2006, 8 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 34, 3426 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 26, 1998, 3009 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 14, 1667 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 2, 169 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 13, 1177 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон) (Российская газета, 2006, 5 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2010, 14 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2010, 30 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 27, 3881 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2011, 22 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2011, 8 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2014, 29 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 28 февралендәге 221 номерлы указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, 3 март, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка техника төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыелмасы, 1993, № 51, 4943 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 1, 997 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында» 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 42, 1997, 4787 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне, аны транспортлау хезмәтләренә тарифларны һәм газкулланучы җайланманы газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырганга түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 2, 175 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләреннән дискриминациясез рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен. Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсе хезмәтләреннән дискриминациясез файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен. Күмәртәләп сату базарының сәүдә системасы администраторы хезмәтләреннән дискриминациясез файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен һәм Электр энергиясеннән файдаланучыларның энергияне кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерү объектларын, шулай ук челтәр оешмаларыныкы һәм башка затларныкы булган электр хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләрен раслау турында» 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 52, 5525 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополия субъектларының хезмәтләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 17, 1887 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашуы хакында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 15.12.2008, № 50, 5971 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси

эшкуарларга карата ел саен планлы тикшерүләр үткәрү планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гомер өчен зарури һәм әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы карары (Российская газета, 2010, 3 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник карау үткәрү турында» 2011 елның 5 декабрендәге 1008 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 50, 7397 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 4, 504 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен ваклап сату базарларын эшләтү, электр энергиясеннән файдалану режимын тулысынча һәм (яки) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 23, 3008 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 44, 6022 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 15 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 1 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 7 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 26 октябрь);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьләр юллау һәм башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган, документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итә торган оешмалардан әлеге документларны һәм (яки) мәгълүматны түләүсез нигездә, шул исәптән электрон формада да, алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 20 апрель);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 3 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килү алымын куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 26 август);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 18, 2633 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары

тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 22 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март);

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Ватаным Татарстан, 2008, 28 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Тоткарланган транспорт чараларын махсус тукталыш урынына күчерү, аларны саклау, кайтарып бирү, аларны бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау чыгымнарын түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2012, 26 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2014, 20 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 28 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №29, 1195 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник карау уздырган өчен түләүнең чик күләмнәрен билгеләү турында» 2011 елның 27 декабрендәге 1079 номерлы карары (Республика Татарстан, 2011, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, №7-8, 0201 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы карары (алга таба – 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы ТР МК карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 7 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (pravo.tatarstan.ru), 2018, 3 октябрь).»;

1.9 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә – тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;»;

2 бүлектә:

2.1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« - дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, гадәттән тыш югары, югары һәм әһәмиятле хәтәрлек категориясенә

кертелгән, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла торган объектлар турында тиешле мәгълүмат.»;

2.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекләренә бирелгән хәтәрлелек категориясенә карап, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр үткәрү түбәндәге ешлыкта гамәлгә ашырыла:

гадәттән тыш хәтәрлек категориясе өчен – елына бер тапкыр;

югары дәрәҗәле хәтәрлек категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый хәтәр категория өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача хәтәрлек категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм биш елга кимендә бер тапкыр;

уртача хәтәрлек категориясе өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм сигез елга кимендә бер тапкыр.

Эшчәнлеге түбән дәрәҗәле куркынычлылык категориясенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр уздырылмый.

Юридик затны һәм шәхси эшкуарны планлы тикшерүне ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләргә кертү нигезе булып билгеле бер хәтәрлелек категориясе өчен билгеләнгән срокның бетүе тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән башлап;

3) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле өлкәдә вәкаләтле дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган хәбәргә ярашлы рәвештә, күрсәтелгән хәбәрне тапшыруны таләп итә торган эшләр башкарылган яисә хезмәтләр күрсәтелгән очракта, эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган көннән башлап.

Табигый монополия субъектларын, электр энергетикасында, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу өлкәләрендә һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынулы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларны планлы тикшерүне Ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләр планына кертү нигезе булып хәтәрлелекнең билгеле бер категориясе өчен билгеләнгән срокның узуы тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерү тшмамланган көннән башлап.»;

5 бүлектә:

5.2.2 пунктның беренче абзацында «административ практика бүлеге» сүзләрен «контроль-ревизия бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.2.3 пунктның беренче абзацында «административ практика бүлеге» сүзләрен «контроль-ревизия бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.2.6 пунктның беренче абзацында «мәгълүматлаштыру бүлеге» сүзләрен «мәгълүмат-техника ягыннан хезмәтләр күрсәтү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.10 пунктның беренче абзацында «мәгълүматлаштыру бүлеге» сүзләрен «мәгълүмат-техника ягыннан хезмәтләр күрсәтү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3.11. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә – тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына кертә.»;

5.4.7 пунктның беренче абзацында «мәгълүматлаштыру бүлеге» сүзләрен «мәгълүмат-техника ягыннан хезмәтләр күрсәтү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.8. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә – тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына кертә.»;

5.5.9 пунктның беренче абзацында «мәгълүматлаштыру бүлеге» сүзләрен «мәгълүмат-техника ягыннан хезмәтләр күрсәтү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5.10. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә – тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына кертә.»;

5.6.9 пунктның беренче абзацында «мәгълүматлаштыру бүлеге» сүзләрен «мәгълүмат-техника ягыннан хезмәтләр күрсәтү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.6.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6.10. Җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә – тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасына кертә.»;

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев